| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.08.2015 № 695

01.01.2012гә кадәр билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә тиешле күпфатирлы торак йортта гражданнар милкендә булган торак бинаны тартып алу турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 26 сентябрендәге 681 номерлы карары белән расланган 2014 елга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча республика адреслы программасын гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе Торак кодексына, Россия Федерациясе Җир кодексына, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, "Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында" 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законга таянып

КАРАР БИРӘМ:

1. Гражданин Тямаев Минталип Вазыйховичтан Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Красноармейская урамы, 69 йорт, 5нче фатир адресы буенча урнашкан торак бинаны сатып алу юлы белән тартып алырга.
2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин